РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» декабрь 2024 ел г. Альметьевск № 4242

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы мәгариф
идарәсенең мәгълүмат-методика
бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте
өчен түләү шартлары турындагы»
2022 елның 16 маендагы 898 номерлы
карарына үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 2 өлеше нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсенең мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы» 2022 елның 16 маендагы 898 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 26 октябрендәге 2465 номерлы, 2024 елның 3 октябрендәге 3220 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарның 1 нче кушымтасында:

2 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Айга база окладының күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яисә «дипломлы белгеч» квалификациясен бирү белән расланган югары һөнәри белем бирү |

заказ № 1-851

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 20 246,00 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 20 251,00 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлек мөдире (җитәкчесе) урынбасары: муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек; структура бүлекчәсе мөдире (җитәкчесе) : муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек; | -<br><br>- | -<br><br>- | 20 329,00<br><br>20 405,00 |

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәгариф идарәсенең мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымтасының «Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Советлар Социалистик Республикалары Союзының, Россия Советлар Федератив Социалистик Республикасының кызыксындыру характерындагы түләүләр күрсәтелә торган ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)» 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 1.12 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| 1.12. | «Яшьлек һәм профессиональлек» күкрәк билгесе |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С. В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе Г.М.Хәбутдинова